ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

27.03.2024
420

**КАРАР**

Татарстан Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына укырга алу турында гаризалар кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 21 маендагы 662 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма 2021 елның 21 маендагы 662 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына укырга алу турында гаризалар кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1.2.1.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 8 пунктында һәм «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» Федераль законның 28.1. статьясында күрсәтелгән балаларга аларның гаиләләренең яшәү урыны буенча дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында беренче чиратта урыннар бирелә».

1.2. Регламентның 1.2. пунктындагы 1.2.1.3. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.1.3. Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган яисә гаиләдә опекада яисә попечительлектә булган, тәрбиягә алган гаиләне дә кертеп, бертуганнары һәм атасы йә анасы башка булган, уллыкка (кызлыкка) алынган абыйсы һәм (яисә) апасы, опекуннары (попечительләре) бу баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) булган балалар яисә ата-анасы (законлы вәкилләре) бу баланың опекуннары (попечительләре) булган балалар укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга өстенлекле кабул ителү хокукына, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, ия була».

1.3. Регламентның 5 нче бүлегенең 5.1 пунктындагы 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында билгеләнгән, муниципаль хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Лист согласования к документу № 420 от 27.03.2024
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 28.03.2024 09:53

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>28.03.2024 - 12:34 | - |